
Ибраһимов алымы



Сөләйманов Р. Әбүгалисина варисы — Якуб Ибраһимов. – Казан, 2007. – 128 б.

«Гасырлар авазы — Эхо веков» журналы укучылары танылган табиб һәм батыр Якуб Хәмзә улы Ибрагимов белән таныш инде. Аның турында халыкара класслы спорт мастеры К. Мохтаров язып чыккан иде[1].

Менә шуңа да «Әбүгалисина варисы — Якуб Ибрагимов»[2] дигән исем астында басылган китапны әлеге тәфсилле язманың дәвамы кебегрәк кабул итәсең. Аның авторы — Якубның авылдашы, Аксубай районының Иске Ибрай урта мәктәбе укытучысы Рамил Сөләйманов — үзенең хезмәтен күренекле галим-хирургның, татарча көрәш буенча Россия спорт мастерының 60 еллык юбилеена багышлаган.

Китапта Я. Ибраһимовның бала чагы, мәктәп һәм студент еллары, аның катлаулы хезмәт юлы, гаилә тормышы киң чагылган. Без исә Казан дәүләт медицина академиясенең травматология, ортопедия һәм нейрохирургия кафедрасы профессоры, медицина фәннәре докторы Я. Х. Ибраһимовның бу китаптагы күпләр өчен билгеле булмаган шөгыле — татарча көрәштә ирешелгән уңышлары турында тулырак мәгълүмат бирергә кирәк таптык.

Автор Я. Ибраһимовның көрәш белән даими шөгыльләнүен 1965 нче елда Казан дәүләт медицина институтына укырга кергәч башлана, дип яза. Ә мәйданда тәүге җиңүләр аңа 1970 нче елда килә — башта ул Аксубай Сабан туеның баш батыры була, «Уңыш» җәмгыяте чемпионатында танылган пәһлеван Данил Галиевны хәлиткеч очрашуда җиңеп, 80 килограммлы үлчәмдә беренче урынга чыга, Татарстан чемпионатында 47 яшендә вафат булган данлыклы батыр Галиевтан кабат өстенлек алып, үз үлчәмендә республиканың иң оста көрәшчесе исемен ала. Ә менә шул ук елны үткән Россия чемпионатында, тактик ялгышлык ясау сәбәпле, Якубка икенче урын белән генә канәгатьләнергә туры килә. Автор бу хәлне батырның үзе белән әңгәмә формасында ачыклый. Без дә сүзне Я. Ибраһимовның үзенә бирик: «Ярыш барышында Та-

тарстан көрәшчеләре көчлерәк булып чыкты. Беренче өч урын өчен көрәш 1965 нче елгы РСФСР чемпионы Илгиз Минһаҗев, Фаил Әхмәдиев һәм минем арада барды. Үзара очрашуда гафу итмәслек хата ясадым. Тәҗрибәм аз булу сәбәпле, Фаил белән килешеп, үзара очрашуны ничьяга — 1:1 гә тәмамладык. Илгиз Минһаҗевне баллар буенча җиңдем. Әмма һич уйланмаган вакыйга булды: Илгиз Минһаҗев Фаил Әхмәдиев белән көрәшергә чыкмады һәм саф җиңү Фаилга бирелде. Нәтиҗәдә, Фаил Әхмәдиевне РСФСР чемпионы итеп таныттылар»[3]. Р. Сөләйманов Якубның күп кенә Сабан туйларында беренче батыр булып калуы, 57 яшьтә ветераннар көрәшендә Идел буе районы Сабан туе батыры булуы турында авылдашы өчен горурланып хәбәр итә. Аксубай районы егетенә озак еллар җиңү китергән көрәш алымы турында исә ул тәфсилләп яза: «Дөньякүләм танылган легендар марафончы Камил Мохтаров (тумышы белән Аксубай районы Кыязлы авылы егете) әйтүенчә, Якуб Хәмзә улы куллана торган көрәш алымы татар көрәш классификациясендә юк. Көндәшеңне җирдән йолкып алып, күкрәк өстенә меңгереп, бер якка әйләндереп салу — көрәшчеләр арасында танылган алым. Егылыр ягына аякларын сузып, көндәшең каршы алым кулланмасын өчен, бик көчле, гайрәтле кутәрү һәм әйләндерү таләп ителә. Бу алым һәрвакыт җиңү китермәскә дә мөмкин.

Әмма... Якуб сине җиргә егып төшерергә ашыкмый, ә киресенчә, күккә таба, өскәрәк чөя. Шулчак — билгесезлек... җир, күк һәм җилкә башы. Җиргә ыргыту җилкә аша, дип уйлыйсың. Ләкин шушы мизгелдә уйларың челпәрәмә килеп, очыш өскә таба дәвам итә... Күтәрелү кайчан тәмамланыр икән? — дип уйлыйсың. Бөтен гәүдә озынлыгына тураеп баса. Ул — бер метр туксан сантиметр. Кулларын өскә күтәреп, көндәшне күк орбитасына чыгара һәм, җилдәй өермә бөтерелгән сыман, әйләнмә хәрәкәт тоясың. Бер караганда, ул сине егарга да теләмәгән, ә ерак очып китмәсен өчен үзеңне тотарга гына теләгән сыман тоясың; аннары һавада өермә кебек спираль әйләнмә хәрәкәт ясап очып, җиргә, сыртыңа ятканыңны сизми дә каласың.

Әлеге көрәш алымы сөңге ыргытучы хәрәкәтенә охшаган. Бер үк хәрәкәтләр: җирдән аерылу, кискен борылыш һәм чөю. Чөю урынына бераз тоткарлану һәм әйләндереп салу, ә сөңге урынына — кеше. Карап торсаң, бик гади һәм матур көрәш алымы дип сокланасың, мин дә кабатлап кулланып карыйм, дисең. Әмма бу алым күпләргә бирелми.

Сөйләүләре буенча, Якуб Хәмзә улы куллана торган көрәш алымын әлегә кадәр берәү дә куллана алмый. Аны Камил Мохтаров “Ибраһимов спирале” дип атый. Дөресен әйтергә кирәк, әлеге алым көрәш классификациясендә теркәлмәгән, әмма көрәшчеләр арасында аны “Якуб алымы” дип йөртәләр»[4].

Р. Сөләймановның «Әбугалисина варисы — Якуб Ибраһимов» китабы — яшь буынга, бигрәк тә татарча көрәш белән шөгыльләнүчеләргә — кыйммәтле бүләк.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Мухтаров К. Прием Якуба, наследника Абугалисины // Гасырлар авазы — Эхо веков. – 2002. – С. 298-303.
2. Сөләйманов Р. Әбүгалисина варисы — Якуб Ибраһимов. – Казан, 2007. – Б. 128.
3. Шунда ук. – Б. 88-89.
4. Шунда ук. – Б. 84-85.

Шамил Рамай,
тарихчы-архивчы

РЕЗЮМЕ

Историк-архивист Ш. Рамай дает обзор книги Р. Сулейманова «Әбугалисина варисы — Якуб Ибрагимов», посвященной профессору кафедры травматологии, ортопедии и нейрохирургии Казанской государственной медицинской академии, мастеру спорта по татарской национальной борьбе курэш Якубу Хамзиновичу Ибрагимову.